**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 30 сентябрендәге 4117 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2015 елның 9 ноябрендәге 3921 номерлы «Казан шәһәре территориясендә рөхсәтсез куелган һәм законсыз урнаштырылган күчемле милек объектларын сүтү һәм күчерү һәм тотылган чыгымнарны кайтару тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль закон, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Казан шәһәре Думасының 2012 елның 7 июнендәге 25-14 номерлы «Казан шәһәре территориясендә рөхсәтсез куелган һәм (яки) законсыз урнаштырылган күчемле милек объектларын ачыклау һәм сүтү тәртибе турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Думасының 2013 елның 16 октябрендәге 18-25 номерлы, 2016 елның 20 апрелендәге 14-6 номерлы, 2018 елның 28 февралендәге 10-24 номерлы, 2019 елның 26 февралендәге 16-32 номерлы, 2019 елның 25 июлендәге 5-35 номерлы, 2019 елның 18 декабрендәге 7-37 номерлы, 2020 елның 21 октябрендәге 7-2 номерлы, 2021 елның 29 июнендәге 7-7 номерлы, 2023 елның 14 июнендәге 6-23 номерлы, 2024 елның 26 апрелендәге 31-29 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 9 ноябрендәге 3921 номерлы «Казан шәһәре территориясендә рөхсәтсез куелган һәм законсыз урнаштырылган күчемле милек объектларын сүтү һәм күчерү, тотылган чыгымнарны кайтару тәртибен раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 27 маендагы 2191 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 2359 номерлы, 2017 елның 21 сентябрендәге 3673 номерлы,

2018 елның 17 апрелендәге 1412 номерлы, 2018 елның 24 августындагы 4683 номерлы, 2019 елның 9 сентябрендәге 3176 номерлы, 2020 елның 8 октябрендәге 2898 номерлы, 2021 елның 26 маендагы 1305 номерлы, 2021 елның 15 ноябрендәге 2986 номерлы, 2022 елның 25 гыйнварындагы 235 номерлы, 2022 елның 17 июнендәге 1851 номерлы, 2023 елның 9 мартындагы 707 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Казан шәһәре территориясендә рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) күчемле милек объектларын исәпкә алу, сүтү һәм күчерү, тотылган чыгымнарны кайтару тәртибен расларга:

- Казан шәһәренең муниципаль милкендәге җир кишәрлекләрендә яисә дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә һәм җир кишәрлекләрендә;

- муниципаль милектәге биналар, төзелешләр, корылмалар эчендә (алга таба – Тәртип) (кушымта);

1.2. 2 пунктта «Казан шәһәре Башкарма комитетының» сүзләреннән соң «исәпкә алу,» сүзен өстәргә;

1.3. 2.2 пунктчада «башка җайланмалар» сүзләреннән соң «, конструкцияләр, механизмнар, төзелеш материаллары, коймалар, башка күчемле милек» сүзләрен өстәргә;

1.4. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетына:

- муниципаль җирне контрольдә тотуны, муниципаль милектән файдалануны контрольдә тотуны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә һәм Казан шәһәре территориясендә сәүдә һәм башка шундый объектларга карата материалларны шундый ук тәртиптә Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты районнарының администрацияләренә тапшырырга;

- рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) күчемле милек объектларын сүтүне оештыру максатыннан Казан шәһәре территориясендә законлы урнаштырылган күчемле милек объектлары исемлекләрен «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастыру һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштыру өчен вәкаләтле органга җир кишәрлекләрен арендалау буенча төзелгән килешүләр, сәүдә объектларын һәм башка объектларны урнаштыруга бирелгән рөхсәтләр турында мәгълүмат

бирергә»;

1.5. түбәндәге эчтәлекле 3(1) пункт өстәргә:

«3(1). «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесенә рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) күчемле милек объектларын сүтүне оештыру максатыннан Казан шәһәре территориясендә законлы урнаштырылган күчемле милек объектлары исемлекләрен «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастыру һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштыру өчен вәкаләтле органга төзелгән килешүләр, сәүдә объектларын һәм башка объектларны урнаштыруга бирелгән рөхсәтләр турында мәгълүмат бирергә»;

1.6. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитетына – сәүдә объектлары өлешендә һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты районнарының администрацияләренә – башка объектлар өлешендә:

4.1. рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) күчемле милек объектларының (алга таба – рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объект) исәбен алып барырга;

4.2. законлы урнаштырылган күчемле милек объектларының (алга таба – законлы урнаштырылган объект) исәбен алып барырга;

4.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының кулланучылар базары өлкәсе өчен җаваплы вазифаи затның һәм законлы урнаштырылган объектлар исемлеген раслый торган тиешле территориаль орган җитәкчесенең хокукый актын әзерләү һәм бастырып чыгаруын тәэмин итәргә.

Законлы урнаштырылган объектлар исемлеген раслау турындагы норматив актны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастыруны һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә;

4.4. Казан шәһәре территориясендә рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) күчемле милек объектларын сүтү, күчерү һәм саклау эшләрен оештырырга һәм билгеләнгән тәртиптә уздырырга;

4.5. гамәлдәге законнар нигезендә Казан шәһәре территориясендә рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) күчемле милек объектларын сүтүгә, күчерүгә һәм саклауга вәкаләтле оешмаларны сайлап алуны гамәлгә ашырырга».

1.7. Казан шәһәре территориясендә рөхсәтсез куелган (законсыз

урнаштырылган) күчемле милек объектларын исәпкә алу, сүтү һәм күчерү, тотылган чыгымнарны кайтару тәртибен әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендәге редакциядә бирергә;

1.8. Казан шәһәре территориясендә рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) күчемле милек объектларын исәпкә алу, сүтү һәм күчерү, тотылган чыгымнарны кайтару тәртибенә 1 номерлы кушымтаны әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендәге редакциядә бирергә;

1.9. Казан шәһәре территориясендә рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) күчемле милек объектларын исәпкә алу, сүтү һәм күчерү, тотылган чыгымнарны кайтару тәртибенә 2 номерлы кушымтаны әлеге карарга 3 номерлы кушымта нигезендәге редакциядә бирергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2024 елның
30 сентябрендәге 4117
номерлы карарына кушымта

# Казан шәһәре территориясендә рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) күчемле милек объектларын исәпкә алу, сүтү һәм күчерү тәртибе

## I. Казан шәһәре территориясендә рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) күчемле милек объектларын исәпкә алу

1.1. Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) күчемле милек объектын исәпкә алуны, сүтүне һәм күчерүне оештыруны, шулай ук Казан шәһәре территориясендә законлы урнашкан объектларны исәпкә алуны һәм аларның исемлеген әзерләүне вәкаләтле орган гамәлгә ашыра:

- сәүдә объектларына карата – Казан шәһәре Башкарма комитетының Куллануччылар базары комитеты (алга таба – Комитет);

- башка объектларга карата – Казан шәһәре Башкарма комитетының тиешле район(-нар)ы администрациясе (алга таба – Администрация).

1.2. Законлы урнаштырылган объектлар исемлеге әлеге Тәртипкә 1 номерлы кушымта нигезендә форма буенча раслана, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- объектны урнаштырырга рөхсәт бирә торган документның реквизитлары;
- объектны урнаштыру адресы;
- объектның төре (профиле);
- объектның мәйданы;
- объектны урнаштыру вакыты;
- объектны урнаштырган зат турында белешмәләр.

1.3. Законлы урнаштырылган объектларның расланган исемлеге ай саен «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштырылырга тиеш.

1.4. Бастырылган исемлекләргә кертелмәгән күчемле милек объектлары рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектлар дип санала һәм сүтелергә тиеш.

1.5. «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба – Дирекция) һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты законлы урнаштырылган объектлар исемлеген төзү өчен атна саен урнаштыруга рөхсәт бирелгән яисә аренда килешүләре төзелгән объектлар турында сәүдә объектларына карата – Комитетка, башка объектларга – администрациягә мәгълүмат юллый.

1.6. Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектларны ачыклау буенча чаралар кысаларында:

1.6.1. Дирекция:

- күчемле милек объектын урнаштыруны күз уңында тоткан гамәлдәге килешү (рөхсәт) булуын тикшерә;

- күчемле милек объектын урнаштыруны күз уңында тоткан гамәлдәге килешү (рөхсәт) булмаган очракта, урынга чыгып, объектны карап чыгуны һәм аны фотофиксацияләүне башкара;

- күчемле милек объектының урнашу урыны һәм урнашу адресы күрсәтелгән объектның фотосурәтләрен муниципаль җирне контрольдә тотуны, муниципаль милектән файдалануны контрольдә тотуны башкару өчен Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетына җибәрә.

1.6.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты:

- күчемле милек объектын урнаштыруны күз уңында тоткан гамәлдәге килешү (рөхсәт) булуын тикшерә;

- күчемле милек объектын урнаштыруны күз уңында тоткан гамәлдәге килешү (рөхсәт) булмаган очракта, урынга чыгып, муниципаль җир контролен, муниципаль милектән файдалану контролен уздыру чараларын башкара;

- вәкаләтле органнан, Дирекциядән рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектлар турында мәгълүмат килгән очракта, муниципаль җир контролен, муниципаль милектән файдалану контролен гамәлгә ашыра һәм Казан шәһәре территориясендәге сәүдә һәм башка объектларга карата материалларны тиешенчә Комитетка һәм Администрациягә бирә.

Муниципаль җир контроле акты, муниципаль милектән файдалануның муниципаль контроль акты, җир кишәрлегенең (күчемсез милек объектының) милек төрен һәм рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектларның характеристикалары турында мәгълүматны күрсәтеп, муниципаль хокукый актларда каралган тәртиптә төзелә.

1.7. Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объект турында

мәгълүмат белән муниципаль җир контроле акты (муниципаль милектән файдалануның муниципаль контроль акты) вәкаләтле органга тапшырылган очракта, рөхсәтсез куелган объектны сүтү һәм саклау урынына күчерү буенча чаралар гамәлгә ашырыла.

1.8. Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектны сүтүне, күчерүне һәм саклауны Комитет (Администрация) тарафыннан гамәлдәге законнар нигезендә сайлап алына торган вәкаләтле оешма гамәлгә ашыра.

1.9. Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектны сүтү вәкаләтле орган кушуы буенча гамәлгә ашырыла. Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектны сүткәндә һәм аны вакытлыча саклау урынына күчергәндә, әлеге Тәртипнең 2 номерлы кушымтасы нигезендә акт төзелә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектны сүтү буенча эшләр башлану һәм тәмамлану урыны, көне, вакыты;

- рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектның факттагы торышы;

- рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектны сүткән һәм күчергән затның исеме;

- сүтелгән объектны саклау урыны;

- рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектны сүтү һәм аны күчерү контроль акты реквизитлары нигезендә башкарыла.

1.10. Акт вәкаләтле зат, мондый объектны сүтүне һәм күчерүне башкарган зат вәкиле, шулай ук объектны саклауга кабул иткән зат вәкиле тарафыннан имзалана.

Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектның хуҗасы яисә аның каршында сүтү башкарылган вәкаләтле вәкиле актка үз имзасын куя.

Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объект хуҗасы яисә аның вәкаләтле вәкиле актта имза куюдан баш тарткан (яисә рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объект хуҗасы яисә вәкаләтле вәкиле аны сүткәндә урында булмаган) очракта, бу хакта, баш тарту сәбәбен күрсәтеп, тиешле тамга ясала.

Сүтү вакытында рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объект хуҗасының яисә аның вәкаләтле вәкиленең булмавы объектны сүтүне гамәлгә ашыру өчен каршылык була алмый.

1.11. Акт өч нөсхәдә төзелә, аларның берсе раслама белән (яисә тапшыру турында хәбәр итеп, заказлы хат белән җибәрелә) рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектның хуҗасына яисә аның вәкаләтле вәкиленә

тапшырыла, икенчесе – Комитетта (Администрациядә) саклана, өченчесе – рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектны саклау өчен җаваплы затка тапшырылырга тиеш.

1.12. Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектның хуҗасы ачыкланмаган очракта, актның ике нөсхәсе Комитетта (Администрациядә) саклана.

1.13. Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектны мәҗбүри рәвештә сүтү эшләрен уздырганда, хокук тәртибен тәэмин итү өчен вәкаләтле орган хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек итәргә хокуклы.

## II. Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) күчемле милек объектларын аларның хуҗаларына кире кайтару

2.1. Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) күчемле милек объектларын (объектның состав элементларын) саклау урыннарыннан хуҗаларына кире кайтару, объект хуҗасы рөхсәтсез куелган (законсыз урнашкан) объект аның милкендә закон нигезендә булуын раслый торган документларны күрсәткәннән соң һәм вәкаләтле органның рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектны сүтүгә, күчерүгә һәм саклауга тоткан чыгымнарын кире кайтарганнан соң, вәкаләтле оешма тарафыннан башкарыла.

2.2. Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектны тапшыру факты рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектның вәкаләтле оешмасы һәм милекчесе (хуҗасы) тарафыннан имзалана торган кабул итү-тапшыру акты белән таныклана.

2.3. Хуҗасы вакытлыча саклана торган объект (милек) буенча сүтү вакытыннан алып бер ай эчендә мөрәҗәгать итмәгән очракта, объект (милек) гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә муниципаль милек дип таныла һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының хокукый актында каралган тәртиптә юк ителергә тиеш.

## III. Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) күчемле милек объектларын сүтүгә, күчерүгә, саклауга, транспортлауга, юк итүгә бәйле чыгымнар

3.1. Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектларны һәм

сүтелгән объектларда табылган милекне сүтү, күчерү, саклау буенча чараларны гамәлгә ашыруга, аларны транспорт ярдәмендә күчерү һәм юк итүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү Казан шәһәре бюджеты акчалары исәбенә башкарыла.

3.2. Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектларны сүтүгә, күчерүгә, саклауга бәйле чыгымнар күләмен исәпләү вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Тәртипкә 3 номерлы кушымта нигезендә, сүтелгән Казан шәһәре территориясендә рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектны саклауга вәкаләтле орган тарафыннан тотылган чыгымнарны исәпләп чыгару методикасына нигезләнеп башкарыла.

3.3. Рөхсәтсез (законсыз) объектларны һәм сүтелгән объектларда табылган милекне сүтү, күчерү, саклау, аларны транспорт ярдәмендә күчерү һәм юк итү буенча чыгымнарны кайтару, аларның хуҗасы тарафыннан гамәлдәге законнар нигезендә Казан шәһәре бюджетына акча күчерү юлы белән башкарыла.

_____________________

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2024 елның 30 сентябрендәге
4117 номерлы карарына 2 номерлы
кушымта
(Казан шәһәре Башкарма комитеты
Җитәкчесе урынбасары/ Казан шәһәре
Башкарма комитетының _________
район(-нар)ы администрациясе
башлыгы боерыгы формасы)

**Казан шәһәре территориясендә**
**законлы урнаштырылган күчемле милек**
**объектлары исемлеген раслау турында**

Казан шәһәре территориясендә күчемле милек объектларын урнаштыруны тәртипкә салу максатыннан, Казан шәһәре Думасының 2012 елның 7 июнендәге 25-14 номерлы карарын, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 9 ноябрендәге 3921 номерлы «Казан шәһәре территориясендә рөхсәтсез куелган һәм законсыз урнаштырылган күчемле милек объектларын исәпкә алу, сүтү, күчерү һәм тотылган чыгымнарны кайтару тәртибе турында»гы карарын үтәү йөзеннән түбәндәгеләрне **йөклим:**

1. Казан шәһәре территориясендә законлы урнаштырылган күчемле милек объектлары исемлеген әлеге боерыкка кушымта нигезендә расларга.

2. Бастырылган исемлекләргә кертелмәгән күчемле милек объектлары рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектлар дип санала һәм сүтелергә тиеш дип билгеләргә.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының ______________________________
(сүтү өчен җаваплы зат)
бүлеге башлыгына Казан шәһәре территориясендә рөхсәтсез куелган (законсыз урнашкан) күчемле милек объектларын сүтүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитеты рәисе (Казан шәһәре Башкарма комитетының __________________ район(-нар)ы администрациясе урынбасары)

_______________________________________ йөкләргә.

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Фамилиясе, исеме, атасының исеме

____________________

Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасарының (Казан шәһәре Башкарма комитетының _____________ район(-нар)ы администрациясе башлыгы) боерыгына кушымта
(Форма)

**Казан шәһәре территориясендә законлы урнаштырылган күчемле милек объектлары исемлеге**

| № т/б | Объектның урнашу адресы | Объектның төре (профиле) | Стационар булмаган сәүдә объекты схемасындагы реестр номеры, урнашу урынының координаталары (булган очракта) | Объектны урнаштырырга рөхсәт итә торган документның реквизитлары | Килешүнең (рөхсәтнең) гамәлдә булу вакыты | Объектның мәйданы | Объектны урнаштырган зат (милекче) турында белешмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2024 елның 30 сентябрендәге
4117 номерлы карарына 3 номерлы
кушымта

**___________ номерлы акт**

Казан шәһәре 20 елның «  »  ____________

Сүтү башланды: ________________ ________________
(дата) (вакыт)
Сүтү тәмамланды: ________________ ________________
(дата) (вакыт)

________________________________________________________________________________
(объектның адресы һәм урнашу урыны)
адресы буенча урнашкан рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектны сүтү һәм күчерү

_______ елның ____________________ ____________ номерлы муниципаль җирне контрольдә тоту акты (муниципаль милектән файдалануны контрольдә тоту акты) _______________________________ .

Сүтү вакытына объектның (төзелешнең) фактик торышы:
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________.

Сүтелә торган объектны (корылманы) ачканда табылган милек: _______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________.

Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектны сүтүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле оешма исеме:____________________________________________
_______________________________________________________________________________.

Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектны күчерүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле оешма исеме:_____________________________________________
_______________________________________________________________________________

Сүтелгән объект һәм анда табылган милек җаваплы саклауга: _________________________________________________________________ тапшырылды.
(объектны саклауга алган предприятие исеме)

Объектны саклауга алган җаваплы зат:

_________________________ _____________________________________________

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазифасы)

Акт 3 нөсхәдә төзелде һәм тапшырылды:

_______________________________________________________________________________

(объектны саклауга алган предприятие исеме)

_______________________________________________________________________________;

- объект хуҗасына (әгәр билгеләнгән булса) яисә аның законлы вәкиленә.

Акт белән таныштым

_______________________________________________________________________________

(рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектның [корылманың] хуҗасы)

_________________________ _____________________________________________

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитеты (Казан шәһәре Башкарма комитетының ___________________________ район(-нар)ы администрациясе) вәкиле:

_________________________ ____________________________________________________

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазифасы)

Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектны сүтүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле оешма вәкиле:

_________________________ ____________________________________________________

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазифасы)

Рөхсәтсез куелган (законсыз урнаштырылган) объектны күчерүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле оешма вәкиле:

_________________________ ____________________________________________________

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазифасы)

_______________________